**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Верхнеуслонского муниципального района**

422570, село Верхний Услон, ул. Чехова д. 18
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Башкарма комитет**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

422570, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18 нче йорт
тел.: (8843-79) 2-12-67, факс: (8843-79) 2-12-67
E-mail: Ispolkom.Verhniy-usl@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ
## КАРАР

от №

2018 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы халкын һәм территориясен яклау чаралары турында

“Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2018 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен яклау чаралары турында” 2018 елның 14 февралендәге 85 номерлы карарын үтәү йөзеннән, 2018 елның язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм халыкны, торак һәм хуҗалык объектларын, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне саклау максатларындаа, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елгы язгы ташу чорында Югары Ослан муниципаль районы халкын һәм территориясен яклау буенча чаралар планын расларга (1 нче кушымта).
2. Югары Ослан районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2018 елгы ташуга каршы чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча эш төркеме составын расларга (2 нче кушымта).
3. Югары Ослан муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә, авыл җирлекләре, предприятиеләре һәм оешмаларының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләренә:

Планда күрсәтелгән су басуларга каршы чараларны үтәүне тәэмин итәргә;

халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән яклау буенча чаралар үткәрүне тикшереп торуны тәэмин итү;

барлыкка килә торган гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы турында» 2004 елның 10 декабрендәге 480 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырырга.

4. Югары Ослан янгын-коткару гарнизоны начальнигына су басу куркынычы булган күренешләр барлыкка килгәндә һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга

Татарстан Республикасы РСЧС территориаль системасының көчләренең һәм чараларының әзерлеген тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Мөлкәт формасына бәйсез рәвештә учреждение, предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2018 елгы язгы ташуның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү буенча чараларның үтәлешен тәэмин итәргә, ташуга каршы чараларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди һәм финанс чаралары резервларын формалаштырырга тәкъдим итәргә.

6. Югары су басу чорына предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда җаваплы хезмәткәрләр, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетында – Югары Ослан муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе эшче төркеме әгъзаларын тәүлек буе дежур торуны тәкъдим итәргә.

7. Югары Ослан районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең эш төркеме җитәкчесенә Планны тормышка ашыру турында 27.03.2018 нче елдан 28.05.2018 нче елга кадәр язгы ташу нәтиҗәләре турында мәгълүмат җиткерергә.

8. «2017 елгы язгы ташу чорында Югары Ослан муниципаль районы халкын һәм территорияләрен яклау чаралары турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 28.02.2017 ел, № 562 карарын үз көчен югалткан дип танырга

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов